**«Туган телем – иркә гөлем».**
**17.02.2021.**

Берләшкән Милләтләр оешмасы карары буенча 21 нче февраль Халыкара туган тел көне буларак билгеләп үтелә. Шул уңайдан бакчабызда «Туган телем – иркә гөлем» исемле китап күргәзмәсе әзерләнде. Әлеге чарада әти – әниләр дә бик актив катнашты. Чара барышында балалар татар фольклорының үрнәкләрен әйтеп күрсәттеләр, табышмакларга җаваплар таптылар, мәкальләрнең дәвамын әйтеп бетерделәр. Шулай ук, «Наза», «Капкалы», «Йөзек салыш» милли уеннарыбызны уйнадык.









